# ФДББС гамәлгә кертү шартларында дәрес

**“Күп белдерүгә караганда аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысы”.**

Г.Ибраһимов.

- ФДББС тормышка ашыру шартларында дәрес проектлаштырганда түбәндәге үзенчәлекләр искә алынырга тиеш:
- Системалы – эшчәнлекле якын килү
- Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлгән булуы
- Универсаль уку гамәлләре үсеше

# ФДББС: үзгәрешләр

- ***А) укытучының дәрескә әзерлегендә:***
- 1 – укытучы катгый кысалардагы структуралы дәрес конспекты куллана
- 2 – укытучы дәреснең сценар планын куллана, укытуда төрле форма, алымнар куллана (технологик карта)

# ФДББС: үзгәрешләр

- ***Укыту максаты***:
- 1 – белем, осталык, күнекмә үзләштерү
- 2 –универсаль уку гамәлләре формалаштыру
- ***Белем бирү эчтәлеге:***
- 1 – Укыту-предмет эчтәлегенә ориентлашу
- 2- Белем бирүдә тормыш мәсьәләрен чишүне кертү
- .

# ФДББС: үзгәрешләр

- ***Укучыларга биремнәр формалаштыру (укучы эшчәнлеген оештыру)***
- *1 – укы, ятла, чиш, күчереп яз, чагыштыр, тап, язып ал, үтә һ.б.*
- *2 – анализла, исбатла ( аңлат), чагыштыр, символлар билгелә, схема һәм модель төзе, дәвам итегез, гомумиләштерегез (нәтиҗә ясагыз), чишү юлларын сайлагыз, эзләнегез, бәяләгез, үзгәртегез, уйлап табыгыз һ.б.*

# ФДББС: үзгәрешләр

- ***Укыту формалары:***
- ***1 – нигездә – фронталь***
- *2 – Төп роль - уку-укыту хезмәттәшлеге*

# ФДББС: үзгәрешләр

- ***Укыту нәтиҗәсе:***
- ***1 – предмет буенча***
- ***2 – предмет буенча,+ шәхесне үсешкә китерә торган һәм метапредмет күнекмәләре, портфолио төзү***
- ***Бәяләү***
- ***1 – төп бәя– укытучы бәясе***
- ***2- үзбәягә, дөрес бәяләүгә юнәлгән. Укучыларның нәтиҗәләрен исәпкә алу***

# Беренче һәм икенче буын стандартларын чагыштыру

| Беренче буын стандартлары (2004) | Чагыштыру линияләре | Икенче буын стандартлары<br>Пр. МОиН РФ N 373 от 6.10.2009 г.<br>(изменен 22 .09. 2011 г. Пр.N 2357 г.)<br>Пр. МОиН РФ № 1897 от 17.12. 2010 г. |
|---|---|---|
| Белем, күнекмә, осталык үзләштерү | Белем бирү максаты | Универсаль уку гамәлләре формалаштыру |
| Укыту-предмет эчтәлегенә ориентлашу | Белем бирү эчтәлеге | Белем бирүдә тормыш мәсьәләрен чишүне кертү |
| Уку эшчәнлеге укытучы тарафыннан билгеләнә | Уку процессын оештыру | Шәхси белем программалары төзү |
| Төп - фронталь | Укыту формасы | Төп роль - уку-укыту хезмәттәшлеге |
| Эчтәлек | Юнәлеш | Нәтиҗә |

# традицион эшчәнлеккә һәм ФДББСка нигезләнеп оештырылган укытучы эшчәнлегендәге аермалар

| Позиция | Традицион эшчәнлек | ФДББСка нигезләнеп оештырылган укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Дәрескә әзерлек | Төгәл структурага нигезләнәнә: укытучы ирege юк. Укытучы дәреслек һәм методик рекомендацияләргә генә таяна. | План сценарий рәвешендә , 30-60 % укытучы ирege: дәреслек һәм методик рекомендация, интернет ресурслар, хезмәттәшлекнең башка формалары |
| Дәреснең төп этаплары | Дәреснең күп вакыты тема аңлатуга һәм ныгытуга китә. | Аңлату дәреснең 20-30%, ныгыту 5-10 % ала, калганы мөстәкыйль эшкә бирелә. |
| Укытучының дәрекә куйган максатлары | Дәрестә планлаштырылган бар нәрсәгә өлгерү | Укучыларның эзләнү, материал туплау, уку бурычын дөрес билгеләү эшчәнлеге оештырыла. |
| Укучыларның эшчәнлеге биремнәрне формалаштыру | Чиш, күчереп яз, чагыштыр, тап,башкар; 93 % - репродуктив | Анализла, дәлиллә, чагыштыр, символ аша билгелә, моделен бир, дәвам ит, гомумиләштер, нәтиҗә чыгар, чишү юлын |

# Дәрес типлары (элекке)

- 1. Яңа тема өйрәнү
- 2. Белем, күнекмә, осталыкны тирәнәйтү һәм камилләштерү дәресе
- Белемнәрне системалаштыру, гомумиләштерү дәресе
- Тикшерү дәресе

# ФДББС буенча дәрес типлары

- 1. Яңа белем ачу дәресе
- 2. рефлексия дәресе
- 3. үстерешле тикшерү дәресе
- 4. белемнәр системасын төзүнең гомумметодологик юнәлгән булуы.

# Универсаль гамәлләрнең төрләре



# Шәхес буларак үсеш күрсәткече

- Тормышта үзбилгеләнүгә әзерлек;
- мораль нормаларны үтәргә әзерлек;
- гомумкешелек кыйммәтләренә адекват мөнәсәбәттә булырга әзерлек.

# Регулятив гамәлләр

- уку мәсьәләсен кую *(мин нишләргә тиеш?),*
- чишү юлларын билгеләү *(ничек эшләп була? болай да, болай да була, тагын башкача эшләп булмыймы икән? дип улый белү);*
- эффектив булганын *(нәтиҗәгә җинел илтә торганын, уңаен)* сайлап ала алу, куелган мәсьәләне чишү;
- үз эшенә контроль ясый (*нишләргә тиеш идем әле, ничек эшләдем? дип кабат уйлый*) белү (үзконтроль);
- бәя бирә *(ничек булды? яхшымы, начармы? акмы,карамы? дигән сорауларга җавап бирә)* белү ; *үз эшенә адекват бәя (үзбәя)*

# Танып-белү гамәлләре

- Уку мәсьәләсе чишелешенең гомуми ысулын формалаштыру;
- үзләштерелгән эчтәлекне һәм чишелешнең гомуми ысулын модельләштерү *(предметлды, график, символлы).*

# Коммуникатив гамәлләр

- *Укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүе .*

# «Эшчәнлек - Деятельность».

- **Эшчәнлек–** танып-белүгә һәм субъектның үз-үзен үзгәртүгә юнәлдерелгән психик активлык формасы
- **Эшчәнлек эчтәлеге: максат,** мотив, ысул, шартлар, нәтиҗә

# «Эшчәнлек бештыру - деятельностный подход»,



# «эшчәнлек»


эшчәнлек төрләре
уен
уку
хезмәт
ЭШЧӘНЛЕК
РЕПРОДУКТИВ
КОНСТРУКТИВ
ИҖАДЫЙ
ЭШЧӘНЛЕК ФОРМАЛАРЫ

# Уку эшчәнлеген оештыруның классик формасы – ДӘРЕС



# Мирза Исмагилович Махмутов

«Дәрес - белем, тәрбия бирү, үстерү бурычларнын хәл итеп, укытучы һәм укучылар катнашында, системалы һәм билгеле бер вакыт аралыгында кулланыла торган укучы эшчәнлеген оештыру формасы. Дәрестә укыту-тәрбия процессының барлык педагогик элементлары катнаша: максат, эчтәлек, чаралар, методлар»

# Максат

- Ирешелергә тиешле нәтиҗә фаразы.
- Максат эшчәнлеккә юнәлеш бирү функциясен үти.

# Чаралар

- белем чыганаклары (дәреслек, белешмә сүзлекләр;
- интернет ...);
- техник чаралар, күрсәтмә һәм тарату материалы;
- такта ( 20 нче гасыр  яисә 21 нче гасыр тактасы);
- укучының эш дәфтәре.

# Танып-белү эшчәнлеген оештыру методлары

*(уку-танып белү процессын оештыру характеры буенча, бу бүленеш авторы М.И.Мәхмүтов):*

- аңлатмалы-күрсәтмәле (объяснительно-иллюстративный )–(у1);
- репродуктив (репродуктивный) - (у1-у2);
- өлешчә эзләнүле (эвристический) - (у2);
- проблемалы ситуация тудыру(проблемной ситуации) (у2-у3);
- Тикшерүле (исследовательский )(у3);

# Уку эшчәнлеген оештыру формалары

- Фронталь;
- төркемдә;
- индивидуаль.

# контроль һәм бәя формалары

- Укытучы контроле һәм бәясе;
- укучыларның үзара контроле һәм бәясе;
- укучыларның үзконтроле һәм үзбәясе.

# Көтелгән нәтиҗәлелекне тәэмин итә торган дәрес структурасы

- **I.Ориентлашу, мотивация этабы**

( мотивация - динамический процесс физиологического и психологического управления поведением человека, определяющий его направленность, организованность, активность и устойчивость.)

- **II. УМ адымлап чишү этабы.**
- **III. Рефлексия, бәяләү этабы.** (рефлексия познавательная - обращение назад, самонаблюдение)

# I. Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.

**Бу этапта башкарылырга тиешле эшчәнлек адымнары:**

- 1. Өй эшләренә анализ. Кайсы өй эшен, ничек эшләгәннәр. Иң яхшы эш кемнеке, ни өчен?
- 2. Белемнәрне тигезләү - актуальләштерү, ягъни бүгенге тема ны үзләштергәндә кулланышка кирәргә тиешле, инде үзләште релгән белем һәм күнекмәләрне искә төшерү.
- 3. Уку мәсьәләсен - бүгенге дәрестә үзләштерелергә тиешле бе лем, күнекмәлерне конкретлаштыру ситуациясе тудыру (Уку мәсьәләсе = дидактик максат).

# II. Уку мәсьәләсен (УМ) чишү этабы.

1. Уку мәсьәләсен (укытучы проблемалы сорауларга һәм биремнәргә бүлә) адымлап чишү оештырыла:

**2. {һәр бирем чишелә→нәтиҗә аерып}нәтиҗәләр гомумиләштерелә;**

- **Нәтиҗә →бергәләп→бер-берсенә→үз-үзләренә сөйләнә.**
- **Укытучы критерий бирә. Укучылар үзбәя куя.**

Гомумиләштерелгән нәтиҗә (н1 + н2+ н3= Н) УМ нең чишелеше була.

Модельләштерү - ысул аерып алу, дәрестә башкарылган эшне кыскача язуда күрсәтү.

# III. Рефлексия, бәя этабы.

1.Рефлексия - дәрестә узган юлны кире узу.

Ягъни, нәрсә эшләргә тиеш идек? (УМ искә төшерелә); ничек эшләдек? (чишү юллары искә төшерелә); нинди нәтиҗә ясадык? (Н = н1 + н2+ н3), дигән сорауларга җавап бирү

2. Дәрестәге эшчәнлеккә Үзбәя.

Укытучы критерий бирә, шул нигездә балалар үз-үзләренә билге куялар, ягъни үз эшчәнлекләренең кайсы критерийгә туры килүен билгелиләр.

Искәрмә. Универсаль критерий:

Нәрсә эшләргә тиеш идек? Ничек эшләдек? Нинди нәтиҗә ясадык? дигән сорауларга

а) терәк конспекттан, (тактадан, эш дәфтәрләренән) файдаланып сөйләп бирә алса - «3»;

б) терәк конспекттан файдаланмыйча сөйлиалса - «4»;

в) терәк конспекттан файдаланмыйча, сүзсез (в уме) үз-үзенә сөйли алса - «5».

Әмма бу универсаль критерий белән бәя бирүгә әкренләп өйрәтү зарур...

3. Өйгә эш алу. (Өйгә эш 3 дәрәҗәдә тәкъдим ителә):

- репродуктив эшчәнлеккә, ягъни класстагы эшкә охшаш, үзләштерелгән белем һәм күнекмәләр таләп ителгән эш (бу эш мәҗбүри - һәркем эшләргә тиеш);
- конструктив эшчәнлеккә - ярым иҗади, ягъни, белем һәм күнекмәлерне аз гына яңа шартка күчерүне таләп иткән эш; бу бирем ихтыярый;
- иҗади эшчәнлеккә, ягъни белем һәм күнекмәлерне яңа җир лектә куалану өчен бирелә; бу эш ихтыярый.

# Системалы-эшчәнлекле якын килү *(системно-деятельностный подход)*

- Укытуда танып-белү эшчәнлегенең ролен тану
- Оештыру формаларының төрле булуы,
- шәхси үзенчәлекләрне исәпкә алу,
- танып-белү эшчәнлегендә хезмәттәшлек формаларының күплеге
- Тикшерү һәм бәяләүнең яңа формалары

# Яңа технологияләр  - стандарт таләбе

- укытучының класс белән хезмәттәшлеге үзгәрә
- Аралашуга  барлык укучылар да катнаша
- Укуның мөһимлеген аңлый
- кабатлау уку һәм гамәли мәсьәләләр  иҗади чишү белән алышына

# Белем бирү технологияләре

*Кешенең белеме һәм психологик үсеше эшчәнлектә генә була ала.*



**ПРОБЛЕМАЛЫ УКЫТУ**

(«УКУ СИТУАЦИЯЛӘРЕ» нигезендә укыту)

*Белем бирү бурычы: укучыларның хезмәттәшлеген оештыру өчен шартлар тудыру*



# Белем бирү технологияләре



ПРОЕКТЛАШ
ТЫРУ

**Триада:**
***ФИКЕР-***
***-тормышка ашыру-***
***-продукт***







# ПРОЕКТ МЕТОДЫ :

- Укучыларда төркемнәрдә эшләү күнекмәсе булдырыла, бер-берсенә булышалар, проектның төп өлешен сайлыйлар, нәтиҗә ясыйлар (доклад, газета чыгару, репортаж, презентация…)
- Укучыларның мәгълүмати чаралар белән эшләренә зур игътибар бирелә ( китапның эчтәлеге; таблицалар, диаграммалар, иллюстрацияләр, белешмәләр, сүзлекләр).

# Белем биру технологияләре



**Нигезе:**
Үзләштерүгә таләпләрне дифференциацияләү:
төп һәм югары дәрәҗәдә

## ДИФФЕРЕНЦИАЦИЯЛӘҮ

**Төп принциплар:**

- таләпләр системасының ачык булуы,
- Эшчәнлек үрнәкләрен күрсәтү,
- төп һәм югары дәрәҗәдә белемнәрнең аермасын билгеләү,
- төп дәрәҗәнең барлык укучылар үзләштерә алуы,
- югары дәрәҗәдәге таләпләрне үзләштерүнең ирекле булуы,
- «Әйдәп баручы» төркем белән эш оештыру,
- бәяләүнең җыелма характерда булуы.(накопительная система оценивания)

# Белем бирү технологияләре



*ЭБР – белем бирү чарасы*

*Экраннан уку*

## МӘГЪЛҮМАТИ ҺӘМ КОММУНИКАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

**игезендә белем бирү:**

үлүмати чараларның барлык укучылар өчен дә ачык

укыту процессында киң куллану,



# ИНФОРМАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯ

Компьютер техникасы һәм программа чаралары ярдәмендә мәгълүматны укучыларга әзерләү һәм җиткерү процессы.

## Информацион технологияләр

**техник чаралар** (компьютер техникасы һәм бәйләнеш чаралары)

төрле максатта кулланылган **программа чаралары**.

**Заманча технологияне куллану укучыларда:**

телгә кызыксыну уята

танып белү активлыгын үстерә

иҗади мөмкинлекләрен камилләштерә

белемнәрен тирәнәйтә

# Информацион технология чаралары кулланып, дәрестә нинди мәсьәләләр чишеп була?

туган телне өйрәнүгә кызыксыну уяту

шәхес тәрбияләү

фикерләү сәләтен үстерү

информацион культура тәрбияләү

укытуның сыйфатын күтәрү

эстетик тәрбия бирү

предметара бәйләнеш булдыру

# ДӘРЕСЛӘРГӘ ӘЗЕРЛӘНҮ ӨЧЕН ПРОГРАММАЛАР





# ЭЛЕКТРОН ДӘРЕСЛЕКЛӘР






Программа турында

Керергә

АВТОР ТУРЫНДА:

# Audiacity

# Windows Movie Maker



# Microsoft  Power Point

**Белемнәрне актуальләштерү**

**Яңа теманы аңлату**

Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру



# Уку-укыту пространствасы







жиһазлау:
- укытучы урыны,
- укучылар эшчәнлеге өчен урын,
- чыгыш ясау өчен урын
- төп такта,
- эш такталары,
- китаплар , башка мәгълүмати чаралар өчен почмак
- аудио- и видеоүзәк
- тарату материаллары белән өстәл
- стендлар, күргәзмәләр һ.б..



**Выготский Лев Семенович** (1896-1934):

*«Для того, чтобы просто преподавать, можно знать чрезвычайно мало, а для того, чтобы направлять собственную деятельность ученика, учитель должен знать чрезвычайно много».*

**Галимҗан Ибраһимов:**

*«Укылган, ятланган нәрсә тиз онытыла... Гакылыбыз, шөбһәләр, ялгышлар, аңлашылмаулар табып, үзе эзләнсен. Менә бу эзләнү – мөгаллим тарафыннан шәкерт рухына салынырга тиешле иң кыйммәтле, иң җимешле орлыктыр»*

***( «Әдәбият дәресләре» китабында, кадимчеләрне тәнкыйтләп язган сүзләре; 1916 нчы ел ).***

**Ризатдин Фәхреддин:** *«...Кадими укыту балаларның гомерләрен генә түгел, остазларныкын да зая итүдер. Әмма үзгәрешләр кертүгә рөхсәт юк. Аз гына тайпылыш та мәдрәсәләргә дәүләт тарафыннан төшерелгән низам (устав) бозу һәм хыянәт дәрәҗәсендәге җинаять булып исәпләнәчәк».* (Р.Ф.Гарәп лөгате вә аның галимнәре.);

**Фатих Әмирхан:** *«Вәгазь һәм бер төркем кысынкы низамнар белән генә шәкерткә бер нәрсәне дә тәлкыйн итү (төшендерү) мөмкин түгел генә дип әйтмим, бәлки ул эшләрне бер төрле нәфрәтлендергеч күрсәтергә генә ярыйдыр, Милли рух кертү. милли рухта тәрбия итү шәкерткә «Менә син милли бул, үзең әнсат иткән милләтне сөй, аңа мәхәббәт ит» дию белән генә була торган бер нәрсә мени ул!»*



# Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!